Саранскта 30 майдан 2 июньгә ка-дәр Ворлдскиллс Россия хәрәкәте форумы узачак, ул дискуссия мәй-данчыкларында экспертларны, бизнес-партнерларны, белем бирv оешмалары һәм дәvләт хакимияте органнары вәкилләрен берләштерәчәк.
Исегезгә тошерәбез, WorldSkills Russia - 2022 милли финалы - 16 яшьтән алып 25 яшькәчә булган урта һәм югары белем бирv учреждениеләре студентлары һәм 16 яшькә кадәрге яшvсмерләр арасында WorldSkills стандартлары буенча илдә ин масштаблы ярышлар. Ярышлар 7 блоктан тора: «Тозелеш һәм тозелеш технологияләре», «Транспорт һәм логистика», «Житештерv һәм инженерлык технологияләре», «Хез-мәт кvрсәtv олкәсе», «Мәгълvмати технологияләр», «Ижат һәм дизайн» һәм «Мәгариф». Аларнын 25е буенча ярышлар кондезге форматта оештырылачак, калганнары - дистанцион.
WorldSkills стандартлары буенча чемпионатлар һонәри белем бирv һәм кадрлар әзерләv системасын, эксперт бергәлекләрен vстерvгә, тер-риторияләрнен инвестицион һәм туристик жәлеп итvчәнлеген арттыруга этәргеч бирә.
Шулай, Мордовиядә 52 компетенция буенча «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia-2022) X тобәк чемпионаты узды.
Саранск автомеханика техникумы (Саранский автомеханический техникум) базасында «Йок техникасына хезмәт кvрсәtv» компетенциясе буенча Темников авыл хужалыгы коллияте «Авыл хужалыгы техникасын һәм жиһазларын эксплуатацияләv һәм ремонтлау» белгечлеге буенча 3 курс студенты Азат Дулатов катнашты.
Оч кон дәвамында ярышларда катнашучыларга Газон NEXT автомобиле, руль идарәсе, тормоз системасы белән идарә итv системасына хезмәт кvрсәtv һәм ремонт ясау белән шогыльләнергә, «КАМАЗ 740» автомобиле двигателен, топ шеекларны һәм гильз цилиндрларны сvтәргә туры килгән конкурсант Азат Дулатовка. Ярыш нәтижәләре буенча ул киеренке авыр корәштә мактаулы икенче урынны яулаган. Киләчәге очен бу ярышнын роле бар. Мордовия Главасы Артем Здунов: «WorldSkills Russia һонәри осталык буенча донья чемпионаты - эшкә урнашу һәм яхшы хезмәт хакы буенча беренче адым». Шулай булачак та.
Азат Монир улы белән аралашканда каян сина йок машиналарын ремонтлау теләге барлыкка килде дип сорадым. Ул:

- Мин vзем Темников районы Тархан авылында туып vстем. Әтием - Монир Шарибжан улы, егерме елдан артык тырышып йок тракторында эшли. Кечкенәдән әтиемнен техникага игътибарлы булырга, аны тозек тотарга кирәклеге турында кvреп тә, янында йореп тә һәм хәтта әтием хезмәт дустын ремонтлаган вакытта, кечкенәдән ук, кирәкле ключларны да биреп тора торган идем. Шуна бvген дә мина теориягә караганда практика дәресләре кvбрәк ошый. Ә соекле әнием, Рәмзия Равиль кызы, белгечлеге буенча укытучы. Ул мина һәрвакыт белемнен коче һәм белемле булырга омтылу теләге тәрбияләп килде.
Бvген Азат Дулатов Темников авыл хужалыгы техникумынын 3 курс студенты, дидем. Теория буенча белем туплагач, жәй-козләрен уку йорты биләгән жирләрдә уныш vстерәләр: чәчvдән башлап иген жыеп беткәнче кыр эшләрендә булалар - я трактор белән чәчv-жыю эшләрендә, я ремонтта. Шулай бу уку йортында студентлар 4 ел белем ала һәм мохтажлык кvргән профессия белгечләре буларак, кон таләп иткән урыннарда эшлиләр.
Монир улы Азат, диплом алгач, армия сафларына хезмәт итәргә исәбе бар. Ватанга тиешле хезмәтен кvрсәткәч кенә профессиясе буенча эшләргә уйлый. Язма героебыз хезмәтне ярата. Авылда хезмәт куймыйча гына яшәп тә булмый. Алар балачактан ук, апасы Алиса белән, ой-йорт эшләрен жиренә житкереп башкарырга ойрәнгәннәр; чонки тәрбия шундый аларда. Зур хужалык белән яшиләр Дулатовлар. Әйтеп китим, Мордовия татарларыбыз, шул исәптәп Дулатовлар да борынгыдан килгән ат vрчетv белән шогыльләнә. Атларнын гажәеп матурлыгыннан һәм боеклегеннән карашларны алып булмый. Атларнын гажәеп матурлыгы, акыллылыгына исен китәр. Аларда махсус энергетика бар, диләр. Бәлкем шулар очен дә Азат атларны бик тә ярата; аларны тәрбияләргә әти-әнисенә ярдәм итә.

Наилә НАСЫРОВА